Иманга юл

# БЕР РӘХМӘТ МЕҢ БӘЛАДӘН КОТКАРЫР

Ирле-хатынлы ике кеше бар иде. Чиксез, чагыштыргысыз саранлыклары белән мәшһүр иделәр. Боларга һичбер кешенең үз гомерендә “Тәңре ярлыкасын, рәхмәт төшсен” дигән сүз әйткәннәре юк иде.

Гомерләренең ахырында, көннәрдән бер көнне ире хатынына әйтте:

- И хатын! Инде без синең белән бу кадәр гомер яшәдек, безнең кулыбыздан һичкемнең бер йотым су, бер кабым икмәк ашаганы юк, һәм “рәхмәт” дигән сүзне ишеткәнебез юк. Саранлык белән мәшһүр булдык, әйдә, бер тапкыр гына булса да, сыерыбызны суеп, шәһәр халкын чакырып кунак итик, - диде.

Хатыны иренең сүзенә риза булды. Сыерларны суеп пешереп, итен табынга куйдылар һәм барча шәһәр халкын чакырдылар. Ул шәһәр халкының һичберсе бу сыер итен ашарга килмәде:

- Безгә саранның ашы җирәнгеч, ашамыйбыз, - диделәр.

Шулай итеп, ахырда алар үкенеч һәм хәсрәт белән бу сыер итен ничек кирәк алай үзләре ашап бетерделәр, тик башы гына калды. Ирле-хатынлы икесе киңәштеләр:

- Бу башны кемгә булса да ашатыйк, һич булмаса, берәрсе ашаса, гомеребез эчендә иллә мәгәр бер мәртәбә “рәхмәт, Тәңре ярлыкасын” дигән сүзне ишетер идек, - диештеләр.

- Әйдә. икебез дә урамга чыгып, берәр кешене эзләп табыйк, шаять берәр гарип-гораба очрар, - дип, урамга чыктылар.

Эзләп йөргәндә ак сакаллы бер карт фәкыйрьгә юлыктылар. Кулларыннан тотып, өйләренә алып кайттылар. Гафулар үтенеп, сыер башын пешереп китерделәр. Ул фәкыйрьне ашый башламас борын кыстый башладылар, ичмаса бер мәртәбә булса да “рәхмәт” сүзен әйтсә ярар иде, дип. Шуннан соң бу фәкыйрь бераз туйгач, болар кыстаганга күрә, бер мәртәбә:

- Рәхмәт, Тәңре ярлыкасын! - диде.

Ире бу сүзне ишетеп сөенде, хатынына әйтте:

- И хатын! Әлхәмделиллаһи, беребезгә бер рәхмәт булды. Һич булмаса, тагын бер генә тапкыр әйтсә иде, - диде.

Шулай итеп, тагын кыстый башладылар. Тагын бер мәртәбә рәхмәт әйтте.

Болар тагын да сөенешеп, ире әйтте:

- И хатын! Сиңа да рәхмәт булды, Аллага шөкер, гомеребездә бер тапкыр ишеттек ләбаса, - дип шат булдылар.

Соңрак бу фәкыйрь сорады:

- Ни өчен мондый сүзләр сөйләштегез?

Ире барча хәлләрне бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Башта үзләренең саранлыклары хакында һәм кешедән “рәхмәт” сүзен ишеткәннәре булмавы турында, аннан соң сыерларын суеп, шәһәр халкын чакырганнары һәм аларның килмәгәнлекләрен баштанаяк сөйләделәр.

Аннан соң ул фәкыйрь әйтте:

- Иншалла, ниятегез яхшы икән. Хак Тәгалә барлык гөнаһларыгызны гафу итәр, - диде. Шунда өйдән чыгып барганда, саран кешене кунакка чакырып, “Фәлән көнне бар”, диде һәм барасы юлын өйрәтте.

- Шул фәлән шәһәрнең шул фәлән тарафыннан китәрсез, аннан узгач, минем юлымда яшел үләннәр үскән булыр, шул үләнле юлдан мине барып табарсыз, - диде.

Бу саран аның чакырганына риза булып, вәгъдә биреп, бармакчы булды. Ниһаять, барырга чыкты. Ул карт әйткән шәһәргә җитте. Шәһәр мәйданында бик күп кешеләр җыелып, һөмай (бәхет) кошы чөяләр иде. Бу саранны туктаттылар.

- Кая барасыз? - дип сорадылар. - Без бүген һөмай кошын чөябез, чөнки падишаһыбыз вафат булды, безгә падишаһ кирәк. Бу һөмайның күңеле кемгә төшсә, аны падишаһ итәрбез, син дә китмә, монда бул, - диделәр.

Бу кеше әйтте:

- Мине фәлән карт чакырган иде, мин анда бармыйча булдыра алмыйм, - диде.

Аннан болар сораштылар.

- Ул сине чакырган кем ул? - диделәр. - Ул карт кайдан, ни җирдән?

Бу кеше шәһәр халкына картның ни сыйфатлы икәнен бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Бу шәһәрнең картлары һәм акыллы кешеләре фикер иттеләр:

- Моның әйтүенчә, бу тәгаен Хозыр пәйгамбәрдер, - диделәр.

Инде без һөмай кошын чөймибез, торып торабыз. Барасы юлыңа бар, вәгъдәңә хилафлык булмасын. Безнең сиңа әманәтебез шул булсын: син ул карттан сорап кайта күр, безнең бу шәһәребезгә падишаһ кем булып, һөмай кемнең башына кунар икән һәм падишаһның кызын кем алыр икән, дип җибәрделәр.

Ул кеше китте. Бая чакырган картның әйтүенчә, юл яшел үлән булып сузылып ята. Моның артыннан күп кешеләр, без дә бу яшел үлән белән барыйк әле, дип бара башладылар. Ул яшел үләнле юл аларга юк булып, кешеләр ни эшләргә белмичә гаҗиз булдылар да кире борылып кайтып киттеләр.

Шулай итеп, әлеге кеше карт янына барып җитте. Карт сахрала бер тауның тишеге эчендәге бер алачыкта Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылып утыра иде. Күрештеләр, сәлам бирештеләр. Хозыр галәйһиссәлам аңа чиктән тыш кадер-хөрмәт күрсәтте. Ул кеше хөрмәт соңында ул шәһәр халкының әманәт сүзләрен тапшырды. Хозыр галәйһиссәлам моның соравына җавапны сораган рәвешенчә бирде һәм әйтте:

- Ул шәһәргә падишаһ шул кеше, кем падишаһлык хәбәрен китерә, - диде. - Вә янә падишаһның кызын шул ук падишаһлык хәбәрен китергән кешегә бирерләр, һөмай кошы да шуның ук башына кунар, - дип, җавабын бирде. Аннан соң хәзрәти Хозыр галәйһиссәлам дога кылды:

- Бу кеше падишаһ булсын, һәм падишаһның кызы моңа насыйп булсын, - дип, кире озатып җибәрде.

Кайтырга чыгып, исән-сау ул шәһәргә җитте. Кайтып җитүе белән, шәһәр халкы аның янына җыелдылар, әманәтләрен сорадылар. Ул аларга болай дип җавап бирде:

- Падишаһ хәбәрен кем йөртә - шул кеше падишаһ булыр, падишаһ кызын да шул алыр.

Шәһәр халкы моның бу җавабын яратмыйча:

- Син картсың, безгә падишаһ булу синең кулыңнан килмәс, - диделәр. - Кемгә кунсаң - шул падишаһ! дип, һөмай кошын чөйделәр. Бер чөйделәр - бер кунды, ике чөйделәр - ике кунды. Өченчесендә дә моның өстенә кунды. Ахырда чаралары калмады, падишаһ иттеләр. Падишаһ кызын да аңа бирделәр.

Күрдегезме, бу кыйссадан гыйбрәт ни булды: бу саран кеше никадәр начар исемле булса да, соңыннан яхшы ниятләр итеп, Хак Тәгалә аны бу дөньяда ук нинди мәртәбәләргә ирештерде. Бер рәхмәт сүзе аркасында янә ахирәттә дә дәрәҗәләргә ирештерсә, гаҗәп булмас иде.

Һәркемгә шул тиешле: “рәхмәт” сүзен никадәр ишетсә дә, тагын ишетер өчен яхшылык эшләүдән туктамасын.

## КЕШЕГӘ ЧОКЫР КАЗЫСАҢ - ҮЗЕҢ ТӨШӘРСЕҢ

Көннәрдән бер көнне Әбүҗаһил Пәйгамбәр галәйһис-сәламне үтерергә явыз ният кылды.

Әбүҗаһил падишаһ углы иде, бик дәүләтле, Пәйгамбәр галәйһисссәламнең үҙ нәселеннән иде, әмма һәрвакыт аңа дошман булды.

Колларына боерды, баскычы төбенә бер тирән баз казытты, ул базның өстен юка гына нәрсә белән каплады. Бер колына кушты:

- Бар, Мөхәммәдне чакыр. Килсен, иман китерәм, - диде. - Аңа әйт, Әбүҗаһил чакырды, сырхау булган, сары зәхмәте тигән, дип әйт, - диде.

Үзе зәгъфранга буянды, сырхау булып ятты. Колы барды, Пәйгамбәргә хәбәр бирде:

- Йә Рәсүлуллаһ! Әбүҗаһилгә сырхау тиде, хәл эчендәдер. Пәйгамбәр килсен, иман китерәм, диде. Аңа сары зәхмәте булган, - диде.

Пәйгамбәр галәйһиссәлам сөенеп, иман өйрәтергә бара иде, тәмам кое авызына җиткән иде. Шул минутта күктән Җәбраил галәйһиссәлам иңнеп килде, әйтте:

- Йә Рәсүлуллаһ! Әбүҗаһил баскычы төбенә кое казыткан, сине һәлак итәргә тели. Сырхау түгел, - диде.

Пәйгамбәр галәйһиссәлам кое авызына җиткәч кайтып китте.

Шунда ук коллары Әбүҗаһилгә хәбәр бирделәр:

- Мөхәммәд кое авызына җиткәч, кире кайтып китте, - дип.

Әбүҗаһилнең бик нык ачуы килеп, үзе торып йөгерде, “кое эченә күтәреп орам” дип, кое авызына таба йөгерде, төшеп китте, коены оныткан иде.

Коллары Әбүҗаһилне чыгарыргап аркан суздылар аркан аңа һич җитмәде. Чөнки Хак Тәгалә җирне карап торучы фәрештәгә боерган иде: “Коеның төбен тәмугка таба тарт!” - дип. Ул фәрештә тартты, Әбүҗаһил тирән китте.

Шәһәр эчендә никадәр бау, чылбыр бар иде - барысын бергә бәйләделәр, кое эченә җибәрделәр, Әбүҗаһилгә җитмәде, хәйран булып, аптыраштылар. Кое төбеннән Әбүҗаһил кычкырды:

- Мине һичкем чыгара алмас, чыгарса мәгәр Мөхәммәд кенә чыгарыр. Барып әйтегез, моннан сәламәт чыгарса, иман китерәм, - диде.

Пәйгамбәргә хәбәр җиткерделәр, “Әбүҗаһил шулай-шулай дип әйтә” дип.

Пәйгамбәр тиз заман барды. Кое эченә үзенең мөбарәк кулын сузды - Әбүҗаһил ябышып чыкты. Чыккач әйтте: Гаҗәп, синең сихерең җир астында да йөри икән, - диде. Котылгач, иман китермәде.

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Сәфәр - Рабиғүл әүүл 2012 миләди йыл**
**1433 һижри йыл.**

| Сәфәр-Рабиғүл-әүүәл | Аҙна көндәре | Декабрь, Январь | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сығыа | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | Йәкшәмбе | 16 | 9.07 | 10.37 | 14.30 | 16.16 | 17.46 | 19.16 |
| 4 | Дүшәмбе | 17 | 9.08 | 10.38 | 14.30 | 16.17 | 17.47 | 19.17 |
| 5 | Шишәмбе | 18 | 9.08 | 10.38 | 14.30 | 16.17 | 17.47 | 19.17 |
| 6 | Шаршамбы | 19 | 9.09 | 10.39 | 14.30 | 16.17 | 17.47 | 19.17 |
| 7 | Кесе йома | 20 | 9.10 | 10.40 | 14.30 | 16.18 | 17.48 | 19.18 |
| 8 | Йома | 21 | 9.10 | 10.40 | 14.30 | 16.18 | 17.48 | 19.18 |
| 9 | Шәмбе | 22 | 9.11 | 10.41 | 14.30 | 16.19 | 17.49 | 19.19 |
| 10 | Йәкшәмбе | 23 | 9.11 | 10.41 | 14.30 | 16.19 | 17.49 | 19.19 |
| 11 | Дүшәмбе | 24 | 9.11 | 10.41 | 14.30 | 16.20 | 17.50 | 19.20 |
| 12 | Шишәмбе | 25 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.21 | 17.51 | 19.21 |
| 13 | Шаршамбы | 26 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.21 | 17.51 | 19.21 |
| 14 | Кесе йома | 27 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.22 | 17.52 | 19.22 |
| 15 | Йома | 28 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.23 | 17.53 | 19.23 |
| 16 | Шәмбе | 29 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.24 | 17.54 | 19.24 |
| 17 | Йәкшәмбе | 30 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.25 | 17.55 | 19.25 |
| 18 | Дүшәмбе | 31 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.26 | 17.56 | 19.26 |
| 19 | Шишәмбе | 1 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.27 | 17.57 | 19.27 |
| 20 | Шаршамбы | 2 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.28 | 17.58 | 19.28 |
| 21 | Кесе йома | 3 | 9.11 | 10.42 | 14.30 | 16.30 | 18.00 | 19.30 |
| 22 | Йома | 4 | 9.11 | 10.41 | 14.30 | 16.31 | 18.01 | 19.31 |
| 23 | Шәмбе | 5 | 9.10 | 10.41 | 14.30 | 16.32 | 18.02 | 19.33 |
| 24 | Йәкшәмбе | 6 | 9.10 | 10.40 | 14.30 | 16.34 | 18.04 | 19.34 |
| 25 | Дүшәмбе | 7 | 9.09 | 10.40 | 14.30 | 16.36 | 18.06 | 19.36 |
| 26 | Шишәмбе | 8 | 9.09 | 10.39 | 14.30 | 16.37 | 18.07 | 19.37 |
| 27 | Шаршамбы | 9 | 9.08 | 10.39 | 14.30 | 16.38 | 18.08 | 19.38 |
| 28 | Кесе йома | 10 | 9.07 | 10.38 | 14.30 | 16.40 | 18.10 | 19.40 |
| 29 | Йома | 11 | 9.06 | 10.37 | 14.30 | 16.41 | 18.11 | 19.41 |
| 30 | Шәмбе | 12 | 9.06 | 10.36 | 14.30 | 16.43 | 18.13 | 19.43 |
| 1 | Йәкшәмбе | 13 | 9.05 | 10.35 | 14.30 | 16.45 | 18.15 | 19.45 |
| 2 | Дүшәмбе | 14 | 9.04 | 10.34 | 14.30 | 16.47 | 18.17 | 19.47 |
| 3 | Шишәмбе | 15 | 9.03 | 10.33 | 14.30 | 16.48 | 18.18 | 19.48 |

# КАЗАНДАГЫ РӘСӘЙ ИСЛАМ УНИВЕРСИТЕТЫНДА БЕРЕНЧЕ КУРСКА КЕРҮЧЕЛӘРНЕ СӘЛАМЛӘДЕЛӘР

**Исламия ЛАТЫПОВА**

Җыелышны ачып, уку буенча проректор Марат хәзрәт Гильманов шәкертләргә тәбрик сүзе әйтте:

РИУның ректоры Рафик хәзрәт Мөхәммәтшин барча килгән шәкертләрне котлап, университетның үзенчәлеге хакында сөйләде, биредә ике бербереенә бәйле гыйлем бирелачәге турында әйтте: шәригать, Ислам, мөселман тормышы яктыртылу белән берлектә дөньяви-теология гыйлеме дә өйрәнеләчәк. Бу вакытлыча җир тормышында шәригать белән дөньяви хәлләрне аерып булмый, алар бер бөтен.

Аның чыгышыннан шунысы билгеле булды: РИУ - Рәсәйдәге бердән-бер дини остазларга бай уку йорты, төрле илдән (Согуд Гарәбстаны, Иордания, Пакистан, Мисыр, Сүрия) гыйлем алып кайтучылар укыта биредә. Әбү Хәнифә мәзһабе буенча хөкем итүчеләр, остабызның эшен дәвам итүчеләр, шәригатьне, Көрьән-Кәримне, хәдисләрне яхшы белүчеләр барлык килгән шәкертләрне шул мәзһабта генә укытачаклар.

Университетның китапханәсендәге Согуд Гарәбстанынан килгән кырык мең китап бар, бу зур байлык, чөнки Казан милли китапханәсендә дә андый китаплар юк.

Рафик хәҙрәт Мөхәммәтшин Идел буенда яшәүче мөселман халкының традициясе турында да ачыклап үтте.

Туган илебездә меңәр еллар буе яшәгән әби-бабаларыбызның гореф-гадәтен саклап калырга кирәк. “Ак әбиләр, ак бабайлар, аксакаллар” сыман балачакта ишетелгән сүзләрне һәр вакытта истә тотарга һәм тормышта да үрнәк итеп кулланырга тиешбез. Ак төс, пакъ төс - сөннәт. Адәм баласы беренче туенда ук (исем кушу) ак биләүгә биләнә. Икенче туенда (никах) - гаилә корганда да ак кием кия, өченче туенда да (мәет) - мәңгелек юлга озатканда - ак кәфенгә төренә. Остазыбыз Рафик хәзрәт әйткәнчә, безнең әбиләр хәтта кара ыштан да кимәгәннәр, андый төсне кулланмаганнар. Кара төс бары тик ир-егетләргә генә хас булган. Алар дөньяви тормышта (очрашуларда, җыелышларда һәм башка вакытта) кара классик костюмны кисә дә, ак күлмәген салмаган. Ә инде дини тормышта (намазда, хаждагомрәдә) киеме ак төстә булган. Юкка гына “киеменә карап каршы ал, ә акылына карап озатып кал”, дими халык. Бу тормыш Аллаһу Тәгаләнең сынавы. Бүгенге көндә, әлхәмдулилләһ, чит илләр белән бәйләнешләр, эшмәкәрлекләр, очрашулар рөхсәт ителде. Чит илдән килгән халыклар дүрт мәзһабкә карый, һәр халык вәкиленең үз гореф-гадәте (традициясе), мәдәнияты. Алар белән дус-кунакчыл булсак та, безгә аларның киеме, гореф-гадәте үрнәк түгел. Без аларны бары тик Аллаһу Тәгаләнең сөекле коллары дип кенә кабул итә алабыз. Әгәр мәдәниятыбызны шәригатьне остазыбыз Әбү Хәнифә өйрәткәнчә яшәп сакласак, бабаларыбыз бездән разый булыр дип уйлыймын.

Фән буенча проректор Рөстәм хәзрәт Батровның үз-аллы укырга, алган белемне остазларның җитәкчелегендә системлаштырырга һәм дә бер гаилә булып яшәргә дигән өндәвен бөтен аудитория бердәм кабул итте.

Тәрбия эше буенча проректор Ибраһим хәзрәт, Ислам фәннәре факультеты деканы Рамазан хәзрәт Курамшин шәригать белән берлектә дөньяви (теология) фәннәрен дә якшы өйрәнергә чакырды.

Аллаһу Тәгалә матурны сөя. Пөхтә, таза кием дә, уйларыбыз да, эшләребез дә, яхшы, матур булганда гына чын ихсан була алабыз.

Аллаһу сөбхәнәһу вә Тәгалә Адәм балаларын төрле төстә, төрле телдә, төрле гореф-гадәттә яратса да, без барчабыз да Аның коллары булу сәбәпле, милләт-ара каршылыклар булдырмаска,дуслыкта яшәргә тиешбез. Журналистика факультеты кураторы Резеда ханым Сафиуллинаның кайнар котлау чыгышыннан: “Гыйлемне алырга, алырга, алырга. Кайчан остаз гыйлем бирер дип көтеп утырмаска”.

Яңа укырга килгән шәкертләрнең берсе РИУ остазларына рәхмәт белдерде һәм шәкерләргә укуда сабырлык теләде.

“Әниләр” мәчетендә өстәмә дәресләр (таҗвид һәм башка) алу мөмкинлеге игълан ителү белән җыелыш тәмам булды.